# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ИЖЕВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ИЖЕВКА ТОРАК ПУНКТЫНДА
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

« 22 » ноябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең
Ижевка торак пунктында гражданнар җыены
нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең 2019 елның 4 октябрендәге 137 номерлы карары белән 2024 елның 22 ноябрендә 15.00 сәг. «2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, карамагында 18 яшькә кадәрге балалары булган аз керемле гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына срокლы хезмәткә чакырылганнардан бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорау буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде

« 1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту, җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу һәм тигезләү, Курорт тыкрыгы, Курорт урамы, Кыр урамы буенча чишмәгә таба, килешү буенча түләү

2) урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуның энергияне саклый торган яктырткычларын сатып алу һәм алмаштыру, шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, генератор сатып алу).

3) торак пункт территориясен төзекләндерү (үлән чабу, ягулык-майлау материаллары һәм килешү буенча хезмәт өчен түләү, карны чистарту, сәхнә түбәсенә каркас-тент сатып алу һәм урнаштыру) .

4) су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау ( суга батыру насослары сатып алу , Юбилей ур., 2 йорт буенча канализация торбасын алыштыру, суга батыру өчен фикаль насос сатып алу)”

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия  катнашучылар исемлегенә 620 граждан кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә  катнашучылар саны 334 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

”Риза” - 334 кеше, “каршы” – 0.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегенең Ижевка торак пунктында гражданнар җыенын узган  дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга

2. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Ижевка авыл җирлегенең Ижевка авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә,  I-II төркем инвалидлардан, карамагында 18 яшькә кадәрге балалары булган аз керемле гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә чакырылганнардан  бер тапкыр бирелә торган түләүне  50%ка киметеп  500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп,  кертергә  һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә.

3. Әлеге карарны Ижевка авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru  һәм

Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Ижевка авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Ижевка авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Ижевка авыл җирлеге башлыгы ________ Р.Т.Мәсәгутова
(имза) (имзаның аңлатмасы)